# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге
Садилово торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15 .11. 2022 ел № 5

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Садилово авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 (ике мен) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Садилово авылында авыл эчендәге юлларга вак таш сатып алу һәм ремонт ясау;

б) Садилово Авылы торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 19 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 10 кеше, бу 52,6%ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 10 катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Садилово торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.“Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Садилово торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000(ике мен) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме”

3. Дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) Садилово авылында авыл эчендәге юлларга вак таш сатып алу һәм ремонт ясау;

б) Садилово Авылы торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ф.Сибгатуллин